ГЛАВА
ШАЛТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШАЛТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2019 ел Шалты авылы № 12

**Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Баулы муниципаль районының «Шалты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

2019 елның 1 декабренә 10:00 сәгатькә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә. Халык җыенын үткәрү урыны - Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Шалты авылы, Совет урамы, 63Б адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда Баулы муниципаль районының Шалты авыл җирлеге Шалты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 250 (ике йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

- Шалты авылы урамнарын кардан һәм чүп үләннәреннән чистарту
- Шалты авылында Совет, Новая һәм Мира урамнары буенча чокырлар ремонты

« ӘЙЕ (РИЗА)» « ЮК (КАРШЫ) »

2. Әлеге карарны, кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, Шалты авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шалты авыл
җирлеге Башлыгы З.Х. Фаткуллин